СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

29 июль, 1998 ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 85 (8242) | Бәясе билгеләнгәнчә

### Газлаштыру - көнүзәк бурыч

# ОЗАК КӨТӘСЕ КАЛМАДЫ

***Узган чәршәмбе көнне районда ТРның газлаштыру фонды башкарма директоры, газ үткәрү белән шөгыльләнүче төп подряд оешмалары генераль директорлары, район җитәкчелеге катнашында үткән семинар - киңәшмә шундый нәтиҗә белән тәмамланды.***



Рәсемдә: Киров урамында газ факелы кабынды.

Аның төп бурычын район һәм шәһәр хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллиң бик гади итеп аңлатты:

- Районны челтәр газына тоташтыруда эшләүче подрядчылар белән җыелышып, башкарган эшкә анализ ясау, мөмкинлекләрне барлау - гомумән, ачыктан - ачык эшлекле сөйләшү.

Һәм алдан ук тиешлесен биреп куярга да кирәк: максатка ирешелде, эшлекле сөйләшү дә булды, уртак фикергә дә килендe, мөмкинлекләр дә барланды...

Әлбәттә, боларга ирешү берничә төп алшартка бәйле иде. Кунакларның бит йомшак сүзгә эреп китә торган беркатлылары түгел, ә реаль эшкә реаль бәя бирергә, хуҗаларның эшкә мөнәсәбәтен бик тиз тоярга сәләтле тәҗрибәлеләре һәм сәләтлеләре килгән иде: ТРның газлаштыру фонды башкарма директоры Җ.М. Минәхмәтов, "Востокмонтажгаз" ачык типтагы акционерлык җәмгыяте генераль директоры В.В.Бартенев, "Газпромстрой" чикләнгән җаваплылыктагы җәмгыяте генераль директоры Р.С.Ахмәров, "ЭСКА" фирмасы (Самара шәһәре) генераль директоры П.И.Ситников һ.б. Бу подрядчылар соңгы ике елда районның байтак төбәгенә газ куанычы биреп, үз ышанычлылыкларын гарантияләргә генә түгел, районның партнер буларак ни күләмдә вәгъдәле, җитәкчелекнең ни дәрәҗәдә эшлекле булуын да сынарга өлгергән халык, безнең белән элемтәне саклаулары өлешчә шуннан да килә дип әйтергә кирәктер. Һәм тагын бер фактор - хакимият башлыгы белән шәхси эшлекле дуслык, аңа ихтирам хисе дә күп мәсьәләләрне уңай хәл итүдә зур роль уйнавын кунаклар берничә кабат ассызыклап үттеләр. Шуңа визитның нәтиҗәле һәм ике як өчен дә файдалы булып узуына боларның һәммәсе үз тәэсирен салды дип уйлыйбыз.

Районны газлаштыруның соңгы ике елдагы колачы күз алдында. 1996нчы елда газлаштыру күләме 22, 1997 елда 37 процент булса, быел районны челтәр газына тоташтыру эшен нигездә тәгәлләү бурычы куела. Аның өчен бүгенге көндә нинди эш алып барыла, нинди проблемалар туа - семинар - киңәшмәдә катнашучыларга якыннан күреп, шулар белән танышу мөмкинлеге тудырылды.

(Ахыры 2 нче биттә).

## САБАН АШЛЫГЫНА ДА ЧИРАТ ҖИТӘ

### "Уңыш - 98" матбугат үзәге хәбәр итә

*Элекке көнне генә үткән республика киңәшмәсендә Президентыбызның авыл товар җитештерүчеләрен яклап әйткән сүзе игенчеләрне дә, терлекчеләрне дә азмы - күпме яхшыга өметләндерер дип ышанасы килә. Югыйсә, быелгы корылыкның китергән һәм китерәсе авырлыклары, беренче чиратта, нәкъ менә авыл кешесенең җилкәсенә ятасы бит. Ә аның әле бүген бар булган иген кырларын эш итеп чыгасы бар. Уңышы елдагыдан шактый чигенке булса да, бер генә басуны да "кысыр" калдырасы түгел бит. Ә моңа кирәк булган ягулыгы һәм башкасы өчен барыбер шул ашлык, башка төр кыр һәм ферма продукциясе белән түлисе. Бүген игенчеләребез бар көчне уҗым культураларын урып -җыеп алуга туплыйлар. Соңгы өч - дүрт көндә уракта "Рассвет", Синдряков исемендәге, Кузнецов исемендәге, Хафизов исемендәге, "Үрнәк", "Татарстан" хуҗалыклары ярыйсы гына эшләп алдылар. "Игенче", "Таң", "Чулпан"да игене урылган мәйданнар ишәя төште, уракка соңлабрак керешкән РСУ ярдәмче хуҗалыгында да уҗым бодаен уру - сугуны тиз тоталар. Сабан культураларына керешеп килүче хуҗалыклар да бар инде.*

*Ә менә уҗым чәчү өчен җир әзерләү мәсьәләсендә бик зур алга китеш юк әле. Дөрес, соңгы өч - дүрт көндә "Рассвет"та, "Таң"да әзер мәйданнар шактый ук ишәйде һәм аларда, шулай ук "Сөлчә", "Үрнәк"тә, шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгында планлаштырылган кадәрнең яртысыннан артыграк мәйдан әзер, "Агрохимсервис" ярдәмче хуҗалыгында исә санаулы гектарларда гына җир әзерлисе калды. Ә менә Муса Җәлил исемендәге, Синдряков исемендәге, "Заря", "Татарстан", "Чулпан", нефтебаза һәм сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыкларында әзер мәйданнар бик ишле түгел һәм күбесендә ул эшнең темпы да бик акрын.*

*Терлек азыгы хәзерләүгә килсәк, соңгы өч - дүрт көндә бер шартлы терлеккә исәпләнгән азык берәмлеге бер центнерга диярлек артты. Витаминлы үлән оны агрегатлары "Заветы Ильича", "Игенче", "Родина", Синдряков исемендәге, "Тәрнәс", Чулпан" хуҗалыкларында көйле генә эшләп тора. Сенаж салуда бу арада "Киекле", Мичурин исемендәге, "Рассвет", "Кондырча", "Татарстан", Кузнецов исемендәге хуҗалыклар кискен талпыныш ясап алдылар. Ә менә Муса Җәлил исемендәге, "Заветы Ильича", "Комбайн", "Үрнәк"тә, РСУ ярдәмче хуҗалыгында алга китеш я бөтенләй юк, я бик аз.*

## Республика сулышы • Район тормышы

### ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕНДӘ - КОНФЕРЕНЦИЯ

***Бөтендөнья Татар иҗтимагый үзәгенең Чаллы бүлеге 25 июль көнне шәһәр мэриясенең Сара Садыйкова исемендәге Концертлар залында милли - сәяси - гамәли конференция үткәрде.***

Бу конференциягә Казанның һәм татарлар яши торган чит төбәкләрнең иҗтимагый үзәкләреннән, республикабыз шәһәрләре һәм районнарыннан һәм шул исәптән бездән дә вәкилләр чакырылган иде. Конференциядә барлыгы 372 делегат катнашты. Көн тәртибендә татар мәдәнияте, тарихы, әдәбияты, матбугат һәм телевидениесе, мәгариф һәм әхлак мәсьәләләре каралды. Депутатлар Фәндәс Сафиуллин, Сүрия Усманова, Мәскәүдән килгән профессор тарихчы Әгъдәс Борһанов, татар милли хәрәкәте лидеры Зәки Зәйнуллин, Кама политехник институты ректоры Әсфәндияр Хәйрушин, Башкортостан татар иҗтимагый үзәге рәисе Закир Хәкимов, Татарстанның атказанган җырчысы Вафирә Гыйззәтуллина һ.б.ларның чыгышлары зур кызыксыну уятты.

### ӘЛМӘТ АВЫЛЫНДА - КВН

***Узган атнада Әлмәт авылы мәдәният йортында зирәкләр, тапкырлар клубының чираттагы очрашуы булды.***

Бу көнне Кизләү, Түбән Нурлат, Зирекле командалары икенче әйләнеш уеннарында көч сынаштылар, ә инде Әмзә һәм Әлмәт яшьләре беренче тапкыр очрашты. Уеннарның бер өлешен Татарстан телерадиокомпаниясе журналистлары "Чулпан" тапшыруында файдалану өчен видеотасмага да төшереп алдылар.

### КОНКУРС НИГЕЗЕНДӘ

**Татарстан территориясендә җир асты байлыкларыннан файдалануга хокук алу конкурсы (ул 17нче июль көнне үткәрелгән иде) уздыру нәтиҗәсендә, җөмһүрият казнасы 600 меңнән күбрәк долларга ишәйде.**

Бу сумма - 12 компаниянең бер тапкыр керткән взносы ул. Аларга бездәге зур булмаган 16 нефть ятмасын үзләштерүгә лицензия биреләчәк. Конкурста Татарстан компанияләреннән тыш, Россиянең "РИТЭК" инновация энергетика компаниясе буйсынуындагы бер бүлеге дә җиңеп чыкты.

### ИСКЕ - МОСКЫДАН - ЯҢА ӘЙБЕРЛӘР

**Түбән Каманың "Эластик" акционерлык җәмгыятендә яраксызга чыккан, искергән пластмасса әйберләрне эшкәртә торган участок эшли башлады.**

Моннан ары әлеге материалдан ясалган әрҗә, мебель, савыт - саба һ. б. бик күп төрле "ашы беткән" эшләнмәләр шушында күпләп кабул ителә. Эшкәрткәннең соңында бу төр чималдан чиләк - чүмеч, су сиптерү шлангы, үсенте утыртыр өчен әрҗә, кием элгеч ише кирәк - ярак ясап, сәүдәгә озаталар. Һәртөрле буяу кушып та җибәргәч, яңа товар үтә матурланып, ямьләнеп китә.

"Эластик"та урнаштырылган заманча җиһазлар Алманиянең "Куаси" фирмасыннан кайтарылды.

(**"Ватаным Татарстан"нан**).

## БЫЕЛГЫ УРАКНЫҢ БЕРЕНЧЕ БАТЫРЛАРЫ

### ДОНСКОВ ТАГЫН АЛДА

**Хафизов исемендәге** хуҗалык комбайнчысы **Александр ДОНСКОВ**ның исеме ел буе урып - җыю чорында популярлашып китә. Быел да Александр Егорович мәһабәт "ДОН"ына утырып кырларга чыкты, бүгенге көндә ул барлыгы 2187 центнер арыш һәм уҗым бодае суктырды инде. Хуҗалыкта ашлык суктыруда икенче күрсәткеч **Мансур НАСЫЙБУЛЛИН** кулында.

**С.ФӘЙЗУЛЛИНА.**

### СЫНАТЫРГА УЙЛАМЫЙЛАР

**Синдряков исемендәге КХАда** игеннәрне суктыруда алдынгылык "Дон - 1500" комбайнчысы **Павел Иванович ВАРЛАМОВ** кулында.

Терлекчелек буенча механик булып эшләүче Павел Иванович 4нче сезон инде урып - җыю чорында комбайнга утыра, кырлар иңли, һәрчак исеме алдынгылар рәтендә була. Быел да ул үз бункерыннан 1120 центнер арыш бушатты һәм бу әлегә хуҗалыкта иң яхшы күрсәткеч.

Ә игеннәрне теземнәргә салуда беренчелек **Андрей Валентинович РОДИОНОВ**та. СК - 5 комбайнында игенче улы Николай белән 138 гектар арышны тезмнәргә салды инде.

Басуларда җанлылык көннән - көн арта, алдынгылыкны саклавы да кыенлаша бара. Әмма беренче батырлар сынатырга уйламыйлар.

**Ю.ВАСИЛЬЕВ.**

***


"Рассвет"тан **Фәнис Вазыйх улы ТӨХФӘТУЛЛИН**, "Дон - 1500"белән арыш сугуда смена нормасын 300 процентка үтәп, барлыгы 1118 центнер ашлык суктырды инде.

***

"Чулпан"нан **Хәлим Кашаф улы КЫЯМОВ** теземнәрдәге игенне җыеп суктыруда смена нормасын 180 процентка үти.

# ОЗАК КӨТӘСЕ КАЛМАДЫ

•(Ахыры.Башы 1 нче биттә).



Моның өчен маршрутны иң киеренке эш барган төбәкләрне кертеп төзеделәр. Ул Елаурдан башланды. Биредә кунаклар полиэтилен торбалардан Заречный - Елаур поселокара газүткәргечен төзү барышы белән таныштылар, бу эш белән шөгыльләнүче "Газпромстрой" җәмгыятенең Нурлат төзү - монтаж участогы эшчеләре хезмәтенә уңай бәя бирделәр. Аннан Заречныйда булып, "ЭСКА" фирмасы егетләренең урам газүткәргечләре сузуын карадылар. Бу төбәктә газлаштыру эше гаҗәеп зур колач белән бара. Челтәр газының килүен тоткарламас өчен, бер үк вакытта Чулпан - Заречный китерү (подводящий) газүткәргече дә тартыла, ул Зур Чирмешән елгасы аша үтүне дә күздә тота. Бу эш белән "Востокмонтажгаз" АҖнең 2нче төзү участогы шөгыльләнә. Егетләргә өмет зур һәм тикмәгә генә түгел: алар инде үзләрен Кәкре Атау, Кычытканлы, Әлмәт, Сәләнгеш, Зүзәйдә эшләп яхшы яктан танытырга өлгергән иделәр. Шуңа бу көнне подрядчылар исеменнән Р.С.Ахмәров алдарак әйткән вәгъдәсен тагын бер кат кабатлады: Елаурда республика мөстәкыйльлеге көнне - 30 августта беренче зәңгәр ут кабыначак!

Әйкенче төбәк - Кәкре Атау халкы бу көнгә ирешүенә әле дә ышанып бетми бугай әле. Ышанырлыкмыни: "Востокмонтажгаз"чылар - прораб Е.В.Минжаев, бригадир А.Н. Краснов җитәкчелегендә биредә эшне нульдән башлап, ай ярым дигәндә беренче газны бирделәр бит. Бу чорда алар 6 км.да тармак челтәре сузып, аны йортлар белән бәйләделәр, 163 йортны газлы итәргә әзерләделәр, ГРПны монтажладылар. Бүгенге көндә биредә 10 йортта челтәр газыннан файдаланалар, 80е - бүгеннән газ кабызырга әзер. Рәхмәтле халык газчыларга нинди хөрмәт куярга белми: бу көнне өендә беренче зәңгәр ялкын күргән Сәгыйровлар кунакларны коймагын пешереп, табынын әзерләп көтеп торганнар.

Семинар маршруты шәһәрнең Киров урамына юл алды. Биредә "Газпромстрой"ның Нурлат төзү - монтаж участогы газчылары Түбән Нурлаттан шәһәргә кадәр 1200 метрлы трасса суздылар, шкаф җайланмасы куйдылар, өрдерделәр һәм Калинин урамы белән бәйләделәр, Калинин урамындагы 27 йортны да алар монтажлады. (Киров урамындагы йортлар - машзавод һәм 2нче СУ карамагында). Шулай итеп, бу трасса шәһәрне Түбән Нурлат белән бәйрәлады. Биредә факелны кабызып, Фатих Сәүбәнович тантанага җыелган тимер юл бистәсе халкына үз сүзен әйтте: "Бистәне ноябрьгә кадәр тулысынча газлы итәргә тырышачакбыз". Мәчет картлары, карчыкларның күзләрендә дә шатлык яшьләре елтырады. "Сезгә дога кылып, исәнлек теләп торабыз, озак эшлә әле бездә!"- диделәр алар хакимнең аркасыннан сөеп.



Шул рәхмәтле мөнәсәбәтне төбәк саен күрергә мөмкин иде. Нурлат элеваторында ашлык киптерү һәм эшкәртү процессын газга күчерү - коллективның еллар буена сузылган хыялы иде. Бу үзгәреш элеваторга чыгымнарны 5 тапкыр кыскартырга мөмкинлек бирүен әйткән идек инде. 4 киптерү җайланмасы быел газ белән эшләячәк. Район җитәкчелеге , коллектив моның өчен күп көч куйган, элеваторны газга күчерү "Татархлебопродукт" холдинг компаниясенең дә быел игътибар үзәгендә булган. Элеватор 15 кешене газ белән эшләргә укытып, әзерләп куйган.Кайчандыр мазуттан каралып утырган котельняда бу көнне заманча җиһазның краннарын боргалауга, куәтле зәңгәр ялкын кабынды - газның рәхәте менә шуннан башлануы иде!

Бу - ел башыннан газга тоташтырылган 18нче объект, диделәр район газчылары.

Газ, газ, газ...

Бу сүз ел әйләнәсенә тикмәгә генә телдән төшмәгән икән. Әнә Төрнәстә дә зәңгәр ут сөенече 10 августтан да соңга калмыйча килер, диләр. "Востокмонтажгаз"ның 2нче СУы бүген эш барышын сурәтли: Төрнәстә 96 йорт, үзәктә - 170 йорт әзерлек стадиясендә. Димәк, газ җибәрү эшен бик тиз тотарга була!



Мондый мөмкинлек Кычытканлыда да бар булып чыкты. Шул ук "Востокмонтажгаз" егетләре эшеннән авыл халкы бик канәгать. Бүген 24 йортта зәңгәр ут янса, тагын 80гә бернинди тоткарлыксыз газ бирергә була. 217 йортлы төзек,уңган Кычытканлы халкы семинарда катнашучыларны олы кунаклар итеп ачык чырай, тәмле сүз, кайнар чәй белән каршылады. Өй хуҗасы С.Нургалиева газлаштыру мәшәкате белән йөргән мәрхүм ире Фаикъ аганы искә төшереп елап та алды: күрсен иде шул рәхәткә тиенгәнен авыл халкының, ничек куаныр иде!



Әйе, куана, чын күңелдән сөенә авыл кешесе бу уңайлыкка һәм аның өчен иң зур рәхмәтне хакимият башлыгына юллый. Ничә еллар нефть өстендә утырган районга газ кертүне нәкъ менә Ф.С.Сибагатуллин җанландырып, тизләтеп җибәрүе беркемгә сер түгел. Шул ук Р.С.Ахмәров аны "зур дустым һәм зур газчы" дип тикмәгә генә атамады. Хаким Арча районында эшләгәндә беренче булып 18км. арада полиэтилен торбалар белән газ үткәрүгә алынган кеше, соңрак Мамадышта, аннан авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек министрлыгында эшләгәндә дә авылларны газлаштыру эшен кыю яклаучы, гамәлгә ашыручы иде. Шуңа Нурлат районында да ул беренче көннәрдән бу "социаль революция"не төп мәсьәләләр рәтенә куйды. Иске Әмзә авылында авыл агайлары белән сөйләшкәндә үзара аңлашулы җылылыкны иң элек шуның белән аңлату дөрес булыр.

Район үзәгеннән ерак бу төбәктә урам трассалары районда беренче булып полиэтилен торбалардан салынган, өйләргә генә җир астыннан корыч торбалар күтәрелә. Бу эшне "Газпромстрой" НСМУсы егетләре башкара. Газчылар 8 йортка газ кабызганнар инде, 32се әзер, диләр. Быел бөтен өйләргә шундый уңайлыкны бирергә вәгъдә итәләр - ничек сөенмәсен авыл кешесе мондый шатлыкка?

Семинарның соңгы тукталышы булган Әмзәдә анда катнашучылар белән берничә сүз алыштык. "Востокмонтажгаз" АҖ генераль директоры В.В. Бартенев районда газлаштыру эшенең барышына канәгатьлек белдерде.

- Быел сезнең газлаштыруны 100 процентка үтәргә мөмкинлегегез бар, күп нәрсә хуҗалык җитәкчеләре, халыкның үзеннән тора,- диде Владимир Васильевич.

-Ә без, үз чиратыбызда, кулдан килгән ярдәмне күрсәтәчәкбез,- диде ТРның газлаштыру фонды башкарма директоры Җ.М.Минәхмәтов. - Әлмәт торбалар заводыннан корыч, "Оргсинтез" аша полиэтилен торбалар табышырга булышачакбыз. Бу безгә республика күләмендә 42 мең фатирны газлаштыру планын үтәргә дә булышачак бит.

Хакимият башлыгы бу сөйләшүгә үз нәтиҗәсен чыгарды.

- Барлык районнар бу эшне күпкә иртәрәк башлаганнар һәм күбрәк отканнар. Соңгыларга акча да, ярдәм дә тыйнаграк була. Әмма күңел төшерергә җыенмыйбыз. Безнең бу социаль сәясәтебезне халык дөрес аңлап кабул итте, активлык белән бу эшкә кушылды. ТРның Дәүләт Советына депутатыбыз Ф.Х.Мөхәммәтшинның да безгә зур ярдәме тиде. Шулай итеп, без быел эшебезне республика җитәкчелеге уңай бәяләрлек дәрәҗәдә куя алдык. Подрядчыларыбыз белән дә эшне аңлашып, бер максатка омтылып алып барабыз. Әмма быел районны 100 процент челтәр газына тоташтыру вәгъдәсен мин бирергә ашыкмас идем. Трассаларны елгалар, күперләр аша чыгарасы бар, кече авылларыбызга да кулыбыз җитеп бетмәде әле. Киләсе елга нурлатлылар тулысы белән арзанлы зәңгәр ягулыктан файдаланырлар дип әйтү дөресрәк булыр - бу безнең өчен реаль максат, шуңа омтылабыз,- диде.

Хакимнең сүзләре газ темасының 1нче номерлы бурычлар рәтендә калуын аңлата иде. Семинарда катнашучылар- подрядчылар, газ сузу өчен җаваплы белгечләр, урындагы җитәкчеләр - һәммәсе шул максатка хезмәт итүнең мәшәкатьле булса да никадәр игелекле һәм рәхмәтле булуына тагын бер кат инанып, конкрет бурычлар белән коралланып таралыштылар. Ә семинарның максаты шуннан гыйбарәт тә иде.

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Рәсемнәрдә: Төрнәс ГРПсында; газга шатланалар - тимер юл бистәсендә, Әмзәдә...**

**Н. АЗИЗОВ фотолары.**

## КЕШЕ һӘМ ЗАКОН • КЕШЕ һӘМ ЗАКОН • КЕШЕ һӘМ ЗАКОН

*Матбугат патруле*



# ЮХКДИ ИНСПЕКТОРЛАРЫНА ГАШЫЙКЛАР БУЛЫРМЫ..?



***Дәүләт автоинспекциясенең кулына ак-лы - каралы таяк (жезл) тоткан, күкрәгенә тамга беркеткән хезмәткәрен барыбыз да ярты чакрымнан таный идек. Дәүләт автоинспекциясе хезмәткәрләре үз киемнәрен генә түгел, ә вәкаләтләрен дә үзгәртәчәкләр. Әлеге реформага Россия Федерациясе Президенты Б.Ельцинның "Юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында" 1998 елның 15 июнендә кабул ителгән 711нче санлы указы сәбәпче булды. Агымдагы елның 3 июленнән башлап ГАИ яки ДАИ - ГИБДД (Государственная инспекция безопасности дорожного движения), баш хәрефләрне татарча җыйсак ЮХКДИ дип исемләнә.***

Дәүләт автоинспекциясе 62 ел дәвамында техника белән идарә итүчеләрнең һәм җәяүлеләрнең мәңгелек мәсьәләсен чишә. Оешып кына килгән чакларында аның бурычы фәкать юл хәрәкәтен көйләү һәм транспорт чараларына күзәтчелектән генә гыйбарәт булса, бүгенге эш фронтлары күпкә киңрәк - юл төзелешенә һәм трассаларның торышына дәүләт күзәтчелеге, транспорт чараларын исәпкә алу һәм теркәү. ДАИның асылына тәңгәл килүче исем билгеләү мәсьәләсе, ниһаять, хәл ителде.

ГИБДД үз эшчәнлегендә законлылыкка, гуманлыкка, кеше һәм гражданнар ирекен саклауга, хәбәрдарлыкка нигезләнәчәк, ә төп бурычы юл хәрәкәтендә катнашучыларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен саклау булачак. Болар "инспектор - техника белән идарә итүче - җәяүле" арасындагы "аңлашылмаучылыклар стенасын" җимерер дип ышаныйк.

Игътибарсыз һәм үз - үзләренә артык ышанучан шоферларга акчалата штраф түләтергә омтылып кына торучы каравылчы түгел, ә төгәл, сатылмас, юлларда теләктәшлек күрсәтергә әзер кеше - ГИБДД хезмәткәре әнә шулай күзаллана.

Эчке эшләр министрының "Россиянең Эчке эшләр министрлыгының Дәүләт автоинспекциясе эшчәнлеген үзгәртү турында" 1998 ел, 1 июль, № 239 әмере моннан ары элеккеге ГАИның төп тигезләмәсе булып торачак. Әлеге документта транспорт чараларын туктату алшартлары җентекләп бәян ителгән. Кыскача гына шулар белән танышып үтик.

**Юл хәрәкәте кагыйдәләре.** Бу өлештә штрафның күләме кагыйдәләрне бозулар санына бәйле. Кагыйдәләрне никадәр күбрәк бозсагыз, штрафның да күләме шулкадәр югарырак булачак. Кагыйдәләрне күп мәртәбәләр бозучыларга, ягъни артык тиз йөрергә яратучыларга, үзләренең игътибарсызлыклары нәтиҗәсендә автотранспортларының страхованиесе взносын арттыру "куркынычы" да яный. Алга таба автотранспортны страховкалау мәҗбүри булачак.

Техниканы төгәл һәм тәртипле идарә итүчеләргә "Авариясез эшләгән өчен" ("За работу без аварий") тамгасы тапшырылачак. Дөрес, әлеге тамга нинди дә булса өстенлек бирми, ә шулай да милиция тарафыннан җылырак мөнәсәбәткә юл ача.

**Юл - патруль хезмәте инспекторы.** Ул урланудагы һәм гай-



ре хокукый максатларда файдаланылучы автомашинаны туктатырга хокуклы. Сезне шулай ук хәрәкәт тизлеге һәм хәрәкәт итү чикләнгән урыннарда, кагыйдәне бозган очракта да туктатачаклар. Автомобиль хуҗасы юл хәрәкәтендә катнашучы башка берәүләргә яки милициягә ярдәм күрсәтергә тартылырга мөмкин.

Машина һәм йөк документларын тикшерү фәкать стационар постларда һәм контроль үткәрү пунктларында (КПП) рөхсәт ителәчәк. Әгәр автомобиль хуҗасының яки андагы пассажирның нинди дә булса җинаятьтә яки авариядә катнашы мәгълүм ителсә, әлеге автомобиль теләсә кайсы урында туктатылачак. Сорау алу ихтыяҗы туган нәүбәттә, юл - транспорт һәлакәтенең яки башка хокук бозуларның шаһиты булган автомобиль экипажы шулай ук тоткарлана.

Юл - патруль хезмәте хезмәткәрләренә юл кишәрлекләре бүлеп биреләчәк, алар үз мәйданнарында "авария була гына күрмәсен" дип җан атып торачаклар.

ГАИны үзгәртеп коруда кире элемтә ысулын куллану да күтелә. Техника белән идарә итүчеләргә (шоферларга) шелтә талоннары бирелә башлаячак, ул талоннарны, инспекторларга ризасызлыгыңны яки рәхмәтеңне язып, ГИБДД бүлекчәләренә тапшырырга мөмкин булачак. Хәбәрләр, һичшиксез, өйрәнеләчәк һәм чаралар күреләчәк.

**Г.ГАЛЛӘМОВА,**
**Казан эчке эшләр идарәсе юл - патруль хезмәтенең пропаганда бүлеге мөдире.**
**("Шәһри Казан"нан).**

# НАРКОМАНИЯ - АК ҮЛЕМ

***Әле кайчан гына наркомания, наркотик дигән сүзләр безнең өчен еракта, каядыр "тегендә" кебек тоелган иде. Киноларда күреп, матбугатта укып шаккатсак та, ул чир безгә дә килер дигән уй башыбызга да кереп чыкмады диярлек.***

***Ләкин юкка икән...***

***Соңгы ике елда наркотик матдәләр куллану нигезендә районда өч яшь кеше һәлак булды.***

- Яшьләр арасында наркотик матдәләр кулланучылар саны арткannan- арта бара. Наркотиклар киләчәк буынның сәламәтлеген тирәннән корыта.

Район һәм шәһәр прокуратурасында шул темага үткәрелгән коалицион киңәшмәгә килгән хокук һәм сәламәтлек саклау органнары, район хакимияте вәкилләренең фикерләре шундый иде.

Саннар һәм фактларга килик дисәк, наркоманиянең үзенчәлеге дә шунда: аңарга кагылышлы төгәл статистика юк. Ул алкоголизм кебек ачык күренми: исе юк, тиешле җайланмасыз кешенең наркотик кулланганмы, юкмы икәнлеген ачыклавы ансат түгел. Шуңа да район мәктәпләреннән 6 укучының исәптә торуын гына наркотик кулланучыларның реаль саны дип булмый.

Район үзәк хастаханәсендә дә хәл шулайрак тора. Бирәдә стационар дәвалау үткәрелми, бары тик ашыгыч ярдәм генә күрсәтелә, наркотик кулланучының наркоман икәнлеген ачыклау мөмкинлеге дә юк, табиб үз күзәтүләре буенча аның наркотиктан исерү- исермәү фактын гына констатацияли ала.

Ә менә прокуратурага килгәндә, саннар төгәл: наркотик матдәләрне саклау һәм әзерләү өчен җаваплылык ту-



рындагы 228нче маддә нигезендә барлыгы 9 кеше хөкемгә тартылган. Иң олысына 39 яшь булса, иң кечесенә 16. Шуларның 7се - балигъ булмаганнар. Суд алар өчен әлегә йомшаграк җәза билгели: 8е шартлы хөкем ителә, берсе ирегеннән мәхрүм ителә.

Бу мәкерле чирне тагын да тирәнгә җибәрмәс, киләчәк буынның аңын томаламас өчен нишләргә, ничек көрәшергә? Бүгенге көндә районда бу җәһәттән нинди чаралар кулланырга? Район һәм шәһәр прокуроры киңәшмәдәгеләргә шул сорауларны юллады.

Мәгариф өлкәсендә, район хакимияте башлыгы урынбасары Н.Х.Абдуллин әйтүенчә, мәктәпләрдә бу эш җайга салынган: яз - көз айларында шул темага багышланган айлыклар үткәрелә, август киңәшмәсендә секцияләрдә бу хакта сөйләнелә һәм башка төрле чаралар уздырыла.

Ә хастаханәләрдә исәптәге яшьләр һәм аларның ата - аналары ай саен әңгәмә, лекциягә чакырыла. 5 - 6 шар кеше занятиеләргә йөриләр.

Район эчке эшләр бүлегенә килгәндә, яшүсмерләр арасында җинаятьчелекне кисәтү бүлеге наркотик кулланучыларны, саклаучыларны эзли, таба һәм еш кына бу мәсьәләдә алда әйтелгән ачыклау кыенлыкларына тара. "Наркоманиягә каршы көрәш мәсьәләсендә һәркемнең эше ачык бүленгән, үз линиясе буенча тирәнтен чаралар үткәрергә кирәк",- ди район эчке эшләр бүлеге начальнигы урынбасары В.Л. Гаврилов. Ләкин район үзәк хастаханәсе табиб- наркологы С.И.Федотов, наркотик кулланучыларны якыннан белеп, аралашкан кеше, гадәти чараларның гына наркомания афәтеннән коткара алмавын кисәтә һәм аңа каршы көрәшү өчен максатчан, системалы эш оештыру мөһимлеген җиткерә.

- Ата - аналарның да, балаларның да бу мәсьәләдә мәгълүматлары бик чикле, шуңа аңа караш та җитди түгел, - ди ул. - Иң аянычы шунда: минем күзәтүләр буенча наркотик белән бер бәйләнгән кеше аңардан арыну турында уйламый һәм тырышмый да, ягъни тормыш рәвешен үзгәртергә дә теләми, ә бары тик ничек итеп җәзадан котылу, органнарга эләкмәү турында кайгырта, шуның белән чирне тагын да тирәнгәрәк яшерә.

Шулай да киңәшмәдә гаиләдә, аннары мәктәптә тәрбиягә басым ясарга кирәк, дигән инану уртак булды. Зиһене булган һәркем аңламый калмас: наркотик матдәләр куллануның ахыры- үлем, ә саклаган һәм әзерләгән өчен - Законның тиешле маддәсе гамәлдә, ягъни төрмәдә урын каралган.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

# МИНЕМ КАДЕРЛЕЛӘРЕМ

"Әткәй - әнкәй - ике бөртек
Энҗегә сез тиңнәрем".

***Әти, әни! Шул сүзләрнең никадәр олы, тирән мәгънәгә ия булганын үзең ана булып бала үстергәндә генә аңлыйсың икән ул. Күптән түгел 50 яшьләрен тутырып Зирекле авылында яшәп ятучы әти - әнием Няmaев Равил белән Рәйсә турында бу язмам.***

Әйе! Җырларда җырланганча, энҗе бөртекләрем сез минем. Чәчләрегезгә ак бәс куна башласа да, тормыш маңгайларыгызга тирән сырлар салса да, минем өчен сездәй гүзәл илаһи затлар җиһанда юк. Тормыш иптәшемә дә, улыма да: "Әти - әни - алар минем күзләрем. Шул күзләрем булганда гына мин күрә алам",- дим. Ходаемнан һәр көн туган саен аларга тигез гомер, тазалык - саулык сорыйм.

Әтием белән әнием гомер юлларын Зирекле авылында узалар. Бик яшьли колхозга эшкә киләләр. Әтием нинди генә техникада эшләми. Әнием сигезенче сыйныфны бетерүгә үк сарыклар фермасына эшкә килә. Ул вакыттагы авырлык, кул хезмәте - без яшьләрнең төшенә дә кергәне юк. Бер - берсен яратышып гаилә корып җибәрәләр. Бу елларда әтием армия сафларыннан кайткан гына була. Тормышлары авыр: ашарга ризык, кияргә кием булмый. Менә шунда кирәк була да инде әтинең тырышлыгы, әнинең уңганлыгы. Гурничә төсле йорт җиткезәләр, терлек - туар, кош - корт асрыйлар. Бер - бер артлы өч бала дөньяга килә. Әти - әни безне укыту, кеше итү өчен бик тырыштылар. Абыем белән мин югары уку йортларында укып, беребез инженер - прораб, икенчебез укытучы булып эшли. Инде үзебез дә әти - әни. Кечкенә сеңлебез әле урта мәктәптә укый. Әти - әни янына еш кайтып йөрибез. Хәзер дә икесе дә колхоз эшендә. Әтием - баш инженер, әнием һаман да хуҗалыкның уңган эшчесе. Алар гомердә дә дәрәҗә күтәрергә омтылып яшәмәгән, беркайчан да байлыкка кызыкмаган. Икесе дә еш кына авырып алалар. Шул вакытта әнием яшьләрен сөртә - сөртә: "Исәнлек - зур байлык ул",- ди.

Гомер дәвам итә, инде үземнең гаиләм бар. Әмма алдымнан яктылык нуры сирпеп әти - әнием бара. Сезнең белән генә, сез булганга гына бәхетле без. Тормыш юлын пар күгәрчендәй пар канат булып үтегез, кадерле әти - әнием!

**Лилия ДАУТОВА.**
**Нурлат шәһәре.**

# АХЫРЗАМАН 30 ЕЛДАН КӨТЕЛӘ,

## ди Америка астрономы Браер Марсден

Аның сүзләренә караганда, 2028 елда безнең планетабыз янышнан бик зур астероид (аркылысы - буе 2 чакрым) очып узарга тиеш икән. Җиргә бәрелү куркынычы да юк түгел. Бу астероид 1997 елда ачылган һәм җир өчен куркынычлы булган 108 күк җисеменнән торган исемлеккә теркәп куелган. Галимнәр компьютерда аның моделен ясап, җиргә бәрелгән очракта безне нәрсә көтәчәген күз алдына китерергә тырышканнар.

Бәрелү мизгелендә үк 1000 километр радиусындагы бөтен нәрсә юк булачак. Коточкыч зур мәйданнарда янгыннар чыгачак, атмосферага бик күп күләмдә көл һәм тузан күтәреләчәк. Ул тузаннар дистә еллар буе җиргә коелып торачак. Кояш нурлары көл - тузан катламы аша үтеп керә алмаячак, шул сәбәпле температура кискен төшәчәк. Җылы яратучы хайваннар һәм үсемлекләр кырылып бетәчәк. Ә инде тузан җиргә утырып беткәч, атмосфера кисәк кенә җылыначак, бөтен бозлыклар эреп, коры җирнең күп өлеше су астында калачак. Җирнең магнит кыры үзгәреп, янартаулар ата башларга мөмкин.

Әгәр дә инде астероид океанга төшсә, коры җирне гигант дулкыннар ялмап алачак, атмосферага су тузаны тулачак.

Америка галимнәре бу бәрелешүне булдырмас өчен "Галәм сакчысы" исемле проект эшләгәннәр. Бу проект буенча 6 зур телескоп космосны өзлексез күзәтеп торачак. Соңрак астероид янында атом бомбасы шартлатырга уйлыйлар.

("Татарстан яшьләре"ннән).




# ӨЙЛӘНГӘННӘР ОЗАҒРАК ЯШИ

Стокгольм галимнәре бик күп тикшеренүләрдән соң шундый нәтиҗәгә килгән. Әле җитмәсә буйдак кешеләрнең белем ягы да саерак булса, үлемгә китерә торган төрле чирләр эләктерү куркынычы тагын да зуррак икән. Галимнәр китергән статистика мәгълүматларыннан күренгәнчә, 1990 - 97 елларда 20 - 34 яшьлек ир - атлар арасында белемсезләр югары белемлеләргә караганда өч - дүрт тапкыр күбрәк үлгән. Югары белемле кешенең шөгыле дә, таныш - белешләре дә, кызыксынучанлыгы да, гомумән, тормыш стиле төрледән - төрле була, ә бу исә сәламәтлек өчен бик зур йогынты ясый.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, аерылган хатын - кызлар ялгызлыкны буйдак ирләргә караганда җиңелрәк кичерәләр.

Тагын бер хәвефле статистика: галимнәр тикшереп өйрәнгән шушы чор эчендә хатын - кызлар арасында үпкә рагы белән авыручылар саны арткан. Әмма шунысы куанычлы: ир - атлар арасында исә бу сан кимегән. Галимнәр моның сәбәбен көчле җенес вәкилләренең дөньяда барган тәмәкегә каршы көрәшүче кампанияләр сүзенә колак сала башлавы белән аңлаталар.

## КИМИБЕЗ

Республикада ел башыннан бирле 12363 сабый дөньяга килгән, 15430 кеше, киресенчә, саубуллашкан. Шулай итеп, халкыбыз өч меңнән артык кешегә азайган. Дөнья мәшәкатьләре басканга күрә яшьләр никахлашырга бик атлыгып тормый күрәсең. Ә менә аерылышучылар саны артканнан арта. Быел 5848 никах теркәлсә, 3946 пар аерылышкан.

(" Татарстан яшьләре"ннән).



«ҖӘЙГЕ ХОЗУРЛЫК»

Н.АЗИЗОВ фотосы.

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Кадерле **әниебез Мингайшә Гөбәйдулла кызы Яруллинаны** юбилее белән тәбрик итәбез, ныклы сәламәтлек, озын гомер, гаилә бәхетләре телибез.

Котлы булсын, әнкәй, туган көнең,
Күзләреңдә нурлар уйнасын.
Бүгенгедәй шат елмайсын йөзең,
Кайгы чаткыларын күрмәсен.
**Кызларың, кияүләрең, оныкларың.**

Бикүле авылында яшәүче сөекле **әниебез Роза Юныс кызы Миннекәеваны** 50 яшь тулу уңаеннан олы юбилее белән котлыйбыз.

Сәламәт бул, гел шат яшә, әни,
Бәхет кунсын күңелең түренә.
Барыбызга канат, терәк булып
Талмый атла гомер түренә.
**Изге теләкләр белән**
**тормыш иптәшең, кызларың,**
**кияүләрең, оныкларың.**

# БЕЛДЕРҮЛӘР

## САТАБЫЗ

**Әйбәт хәлдәге ВАЗ - 2103.** Яңа Иглайда Илшат Хөсәеновка мөрәҗәгать итәргә. Тел.: 2-36-11.

***

**Чистарту корылмалары ягында гараж, нигезе һәм материаллары белән участок.** Тел.: 5-33-64.

***

**Цинкланган калай: шомасының бер табагы - 80, кабыргалысыныкы - 85 сум; 3 мм.лы металл, табагы 200 сум.**

Тел.: 2-13-69, 2-15-89, теләсә кайчан. Акчаны күчереп түләргә була, бартер мөмкин. Б - 97 сер. № 245697 лицензия.

***

**Шәһәр үзәгендә ике бүлмәле фатир.**
Адрес: Чапаев ур., 9 - 15, кичке 7дән соң.

***

**Южная урамында 25нче йорт.**

***

**80 х 50 х 10лы боҗра. Яңа Иглайда 14 сутый җире белән иске йорт.** Суворов ур., 105 адресы буенча Фатыйма Сингатуллинага мөрәҗәгать итәргә.

***

**Гоголь урамында 20нче йорт.**

***

**Запас частьләргә "Москвич - 412", кыйммәт түгел.** Адрес: К.Маркс проспекты, 6 - 7.

***

**Югары сортлы он - 85 сум, китереп бирәбез.**
Тел.: 5-24-97.

***

**Аксубай эшчеләр поселогында торак йорт (бакчасы, яңа мунча бурасы бар) һәм бөтен уңайлыклары белән бер бүлмәле фатир.** Адрес: Аксубай эшчеләр поселогы, Октябрь ур., 31 - 7, теләсә кайчан.

***

**НГДУ ЖКХсы артында капиталь гараж.** Тел.: 5-19-96.

***

**1986 елгы ВАЗ - 21063.** Тел.: 5-17-16.

***

**Ашыгыч төстә шәһәр үзәгендә ике бүлмәле фатир.** Тел.: 5-24 -59.

***

**Шәһәр үзәгендә ике бүлмәле фатир. Базы белән сарае бар.** Адрес: Козлов ур., 14 - 13.

***

**Персональ компьютер, кыйммәт түгел.**
Тел.: 5-36-50, кичке 5тән соң.

## САТАБЫЗ, АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Әфган поселогында төзү материаллары белән участок, кыйммәт түгел. Куйбышев урамындагы өч бүлмәле фатирны - яхшыртылган планировкалы өч бүлмәле фатирга (өстәмә түләп), вариантлар мөмкин.**
Тел.: 2-15-42, кичке 6дан соң.

## АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Кемерово өлкәсенең Ленинсккузнецк шәһәрендәге фатирны - Нурлаттагыга.** Адрес: Завод тыкрыгы, 3 - 3.

***

**Димитровградтагы йортны - Димитровградта бер һәм Нурлатта ике бүлмәле фатирларга.**
Адрес: Маяковский ур., 31, кичке 5тән соң.

***

**Совет урамындагы йорттан 4 бүлмәле фатирны - ике һәм бер бүлмәлеләргә.**
Тел.: 2-15-82, кичке 7дән 8гә кадәр.

***

**Зәй - 2 шәһәрендәге ике бүлмәле фатирны - Нурлаттагы шуңа тиңгә.** Адрес: Совет ур., 187 - 79.

# БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА. БЕЛДЕРҮЛӘР.

***ЧИКЛӘНГӘН ҖАВАПЛЫЛЫКТАГЫ "МАРКЕТИНГ ХЕЗМӘТЕ ДЕПАРТАМЕНТЫ" ҖӘМГЫЯТЕ ХАЛЫККА, ПРЕДПРИЯТИЕЛӘРГӘ, ОЕШМАЛАРГА ҺӘМ ХУҖАЛЫКЛАРГА КИҢ АССОРТИМЕНТТА ТОВАРЛАР ҺӘМ ЗАПАС ЧАСТЬЛАР ТӘКЪДИМ ИТӘ:***

***тракторларга запас частьлар, К - 700, МТЗ - 80 тракторларына, трактор арбаларына резина, "Нива", "Дон - 1500" комбайннарына, МТЗ - 80 тракторларына, КамАЗларга каешлар, СМД - 60, СМД - 14 һәм КамАЗ двигательләренә һава фильтрлары, Т-150, "Дон - 1500" һәм КамАЗларга май фильтрлары, МТЗ - 80, А - 41 двигательләренә ягулык фильтрлары, подшипниклар, роторлы пычаклар, электродлар, ПС - 40 припое, рубероид, 4 кВтлы электр теннары, сыек пыяла, бау, ЛБ - 80 лампалары, серкә кислотасы, 15, 20ле вентильләр, диэлектрик ботылар, киҗе - мамык перчаткалар, сырган курткалар, җылы костюмнар, ак халатлар, противогаз, саклану күзлекләре, сигаретлар һ. б.***

***Предприятиеләр, оешмалар һәм хуҗалыклар белән исәп - хисап бартер буенча, ә халык белән түбән бәядә акча түләп ясала.***

***Барлык сораулар белән түбәндәге адрес буенча мөрәҗәгать итәргә:***

*Нурлат шәһәре, Лесосклад урамы, 1,*
*тел.: 5-39-31.*

## ТӨРЛЕСЕННӘН

**Мебель ремонтлыйбыз.** Тел.: 5-19-80.

***

**Фатир биреп торам, бәясен алдан түләргә.**
Адрес: Завод ур., 26 - 15.

***

**"Урал" мотоциклы сатам. Суыткычлар ремонтлыйм.** Тел.: 5-41-19.

***

**"ФИСКО" фирмасына төзү материалларына заказ биргән дәүләт предприятиеләре, акционерлык оешмалары һәм шәхси затлар, шулай ук Чабаксардан килә торган тышлагыч кызыл кирпеч алырга теләүчеләрнең** 5-20-72, 5-22-37, 2-17-53 телефоннары буенча шалтыратуларын сорыйбыз.

## *Эшкә чакырабыз*

**"ВИГСТМ" ачык акционерлык җәмгыяте филиалының Нурлат хуҗалык исәпле төзү - монтаж участогына квалификацияле сантехниклар, электр һәм газ белән эретеп ябыштыручылар, электриклар (3600 кВт ка кадәр рөхсәт белән) кирәк.**

Адрес: Совет ур., 145.

## *Ярминкәгә чакырабыз!*

**31 июльдә иртәнге сәгать 9дан кичке 4кә кадәр Ульян күн фабрикасы Нурлат район мәдәният йортында аяк киемнәре сату үткәрә.**

## *Идел Буе регональ наркология үзәге*

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.*

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга - 31 нче июль һәм 14нче август көннәрендә, көндезге сәгать 11дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр: Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.
Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2337 данә. 3112